РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«03» июль 2023 ел Олы Кайбыч ав. № 204

«Коррупциячел хокук бозулар кылган өчен Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләренең җаваплылыгы турында» 2013 елның 28 гыйнварындагы 153 номерлы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 13 июнендәге 258-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

**1.** «Коррупциячел хокук бозулар кылган өчен Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләренең җаваплылыгы турында» 2013 елның 28 гыйнварындагы 153 номерлы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

кушымтада:

1 пунктның 1.3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. дисциплинар түләтүләрне куллану һәм бетерү тәртибе, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә.»;

2.5 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясы нигезендә җирле үзидарә органының коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау бүлеге тарафыннан яисә Россия Федерациясе Президенты Администрациясенең вәкаләтле бүлекчәсе тарафыннан үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре турында доклад;».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы Башлыгы А.И.Рәхмәтуллин